


Шәһәр халкына күбрәк «Россия» к/т дип билгеле булган Саранск визуаль сәнгать үзәге базасында Артист йорты ачылды. Анын беренче кунаклары тирә-як мәктәп укучылары һәм музыка училищесы студентлары булды.
Артист йортында жыелганнарны Мордовия Республикасы Главасы Артём Здунов исеменнән Республика Хокүмәтенен беренче вице-премьеры Галина Алексеевна Лотванова яна мәдәни үзәк ачылу белән котлады.     - Профессиональ һәм үзешчән башкаручыларны ижади тормышка ашыру очен пространство барлыкка килүе бик яхшы, - дип билгеләде Галина Алексеевна. Һәм Артист йорты эшчәнлегендә бернинди формальлек булмавын, сәхнә осталары биредә яшьләр белән тәжрибә уртаклашуларын, үзләрен күрсәтергә теләүчеләр үз идеяләрен тормышка ашыру момкинлеге алуларын теләде.
- Артист йортынын торле яшьтәге кешеләрне жәлеп итүе моһим. Эшләгез, кыюланыгыз, яна офыклар ачыгыз! Биредә һәркемгә унайлы булсын, - диде Галина Алексеевна Лотванова.
Театр сәнгатенен республика бү-леге житәкчесе Владимир Шарапов киләсе елда театр сәнгатен тудыручы торле һонәр ияләрен берләштерүче ижтимагый оешма - РФ Театр эшлеклеләре берлегенә 150 ел тулуын искәртте. Һәм Россиянен халык артисты Владимир Машков, Гомумроссия СТД житәкләүче, ил тобәкләрендә Артист йортын ачу инициативасы белән чыккан тәкъдим Россия Президенты Владимир Путиннын хуплавын әйтте. Артист йорты эксперименталь куелышлар ясау һәм халыкка күрсәтү мәйданчыгы буларак та, белем бирү курслары, мастер-классслар, сәхнә осталары белән очрашулар үткәрү очен мәдәни үзәк буларак та уйланыла.
Саранск Артист йорты тормышындагы беренче вакыйга - язмышы Мордовия рус драма театры белән тыгыз бәйләнгән Мордовиянен халык артисты Николай Большаков белән шәһәр халкынын ижади очрашуы булды.
Ә рәсми тантанага сәгать ярым кала «Россия» к/тнын беренче катындагы холлда балалар әкияти сихерчене һәм толкене уратып алдылар. Күршедә балалар театр курчакларынын торле торләре белән идарә итү серләрен үзләштерделәр һәм рәссам-бутафорлар ярдәмендә Яна ел открыткалары ясадылар. Икенче кат фойесында Мордовия рус драмасы актерлары житәкчелегендә яшүсмерләр кылыч белән фехтовкаларга һәм импровизацияләнгән сәхнәдә бер-берсе белән аралашырга ойрәнделәр. Укучылар арасында аеруча популяр бутафор киемнәрен киеп, видеокамерада берәр танылган әсәр сәхнәсен уйнарга момкин иде.

*(Фото - с официальной страницы Русского драматического театра РМ в ВКонтакте)*